**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июль № 512

г. Казань

«Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында

«Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\512.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июль, 512 нче карары белән расланды

«Халыкара программалар дирекциясе»
автоном коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары нигезендә эшләнде һәм «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасына (алга таба – Дирекция) субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Дирекциягә уставында каралган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының (алга таба – Вәкаләтле орган) бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия алу өчен Дирекция Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча заявканы;

гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

Дирекция эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чыгымнар сметасын.

5. Субсидия бирү Вәкаләтле орган һәм Дирекция арасындагы субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Вәкаләтле орган раслаган форма буенча әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны Вәкаләтле органга тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, аннан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне Дирекция тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, законнарда каралган очраклардан тыш, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю, Дирекциянең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, Дирекциянең әлеге Тәртип шартларын үтәве турындагы нигезләмәне үтәвенә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә Дирекциянең ризалыгы күздә тотыла.

6. Вәкаләтле орган, әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күчү вакытларын исәпкә алып, килешүне төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне Дирекциянең хисап счетына күчерә.

7. Дирекция Вәкаләтле органга килешүдә күздә тотылган формада һәм тәртиптә субсидиядән файдалану турында хисап тапшыра.

8. Субсидия түбәндәге очракларда Дирекция тарафыннан Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия бирү шартларын үтәмәү;

субсидиядән максатка ярашсыз файдалану;

субсидия алу өчен Дирекциянең дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыруы.

9. Килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемենә кире Дирекция тарафыннан кайтарылырга тиеш.

10. Дирекция әлеге Тәртипнең 8 нче һәм 9 нчы пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидияне кире кайтару вакытларын бозганда, Вәкаләтле орган кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемենә үзләре кайтарудан баш тартсалар, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

11. Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары Дирекциянең субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

12. Вәкаләтле орган субсидиядән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә башкара.

F:\KARAR\2016\512.docx